

# 1897 елгы халык исәбен алу һәм Алабуга өязе мөселман татарлары

Берничә ел элек кенә илебездә булып узган халык санын алу белән бәйләнештә килеп туган вазгыять — мондый чараның никадәр катлаулы икәнлеген күрсәтте. Беренче карашка статистик бер гамәл кебек кенә тоелса да, аның милли һәм дини мәсьәләләргә кагыла торган үзенчәлекле сәяси мәшәкать икәнлеге тагын бер тапкыр расланды.

Моннан 110 ел элек Бөтенроссия күләмендә үткәрелгән кеше исәбе алу вакытындагы хәлләр тагын да катлаулырак булган. Бу каршылыкның, әлбәттә, тарихи сәбәпләре бар. Гомумән, хөкүмәтнең нинди дә булса рәсми кәгазьләренә язылудан татар халкы бик өркегән. Чөнки Казан дәүләте басып алынганнан бирле, максатчан алып барылган көчләп һәм алдап-йолдап чукындырулар, мөселман динен тоткан татарларны бик сагайткан.

XIX гасыр ахырындагы исәп алу, аңа кадәргедән аермалы һәм үзенчәлекле булган. Аны үткәрү турында император әмере 1895 елның 5 нче июнендә чыккан. 1897 елга хәтле әлеге зур эшкә ил күләмендә әзерлек һәм халык арасында аңлату үткәрелгән. Россиядә яшәгән христиан булмаган халыклар, аерым алганда мөселман татарлар, моңа шомланып караганнар. Хөкүмәтнең бу чарасы гасырлар буе дәвам иткән көчләп чукындыру һәм руслаштыру сәясәтенең чираттагы бер гамәле дип кабул ителгән. Татарлар яшәгән кайбер төбәкләрдә каршылык күрсәтүчеләр тарафыннан чуалышлар, баш күтәрүләр оештырылган. Алар полиция һәм хәрби командалар ярдәмендә бастырылганнар. Болганышларны оештыручыларга җәзалар бирелгән. 1897 елгы халык исәбен алуга бәйле вакыйгалар татар халкының авыз ижатында да, әдәби әсәрләрдә дә чагылыш тапкан[1].

Россия мөселманнарының дини идарәсе (Мәхкәмәи шәргыя)* мәсьәләнең көтелмәгән сәяси һәм дини төсмерен йомшарту һәм асыл максатны аңлату йөзеннән татар һәм рус телләрендә махсус циркуляр бастырып тараткан. 1896 елның 18 июлендә мөфти имзасы куелган мөрәҗәгать, мөселман ахуннары һәм имамнарына җибәрелгән. Гу-

* Ул чорда рәсми рәвештә «Мәхкәмәи шәргыяи Оренбургыя» дип аталган оешманың исемен бу мәкаләдә Диния нәзарәте дип язуны мәгъкуль күрдек.

бернаторлар исеменнән дә татар һәм рус телләрендә шуңа охшаш мөрәҗәгатьләр таратылган.

Россия империясенең татарлар яшәгән төрле губерналарында булган каршылык хәрәкәте фән әһелләре тарафыннан аерым бер күләмдә өйрәнелгән. Тарихчы Илдус Заһидуллинның 1897 елгы халык исәбен алу һәм Казан губернасы татарлары турында махсус тикшеренүе бар[2]. Автор бу хезмәтендә Вятка губернасы турында да кыскача язып үткән. Губерна идарәсенең мөселманнар белән эш йөртүдә алдан күрүчәнлеген һәм сакчыл мөнәсәбәтен уңай яктан бәяләп (төгәллек өчен өземтә китаптагыча бирелә): «В плане воздействия на татарских крестьян печатным словом более дальновидной и предусмотрительной оказалась администрация соседней Вятской губернии. Ее начальник Клингенберг распространил среди мусульман обращение с гарантией их религиозных прав в связи с проведением переписи населения» — дип яза[3]. Нәтиҗәдә, бу китап белән танышкач Вятка губернасында перепись тыныч кына үткән дигән тәэсир кала.

Губернаторның ул мөрәҗәгатендә мөселманнарның диннәренә һәм мәктәп-мәдрәсәләренә бернинди тыкшыну булмаячагы әйтелгән. Бу документ үрнәгендә шундый ук эчтәлектәге мөрәҗәгать Казан губернасында да таратылган. И. Заһидуллин Казан губернаторы П. А. Полторацкийның бу белдерүе, үзгәртелмичә, Вятка губернаторының кыннан сүзгә-сүз күчереп бастырылган дисә дә[4], бер сүздә генә, әмма әһәмиятле аерма бар. Вятка губернаторының «...каждый хозяин должен без всякого страха давать *показания* счетчикам» (курсив безнеке. — *Р. М.*) сүзләре Казан губернаторы текстында «...давать *ответ* счетчикам», — дип йомшаграк сүз белән алыштырылган.

Хакыйкатьтә, Вятка губернаторының «алдан күрүчәнлеге» турындагы фикер дөреслеккә туры килеп бетми. Чөнки губернаторның бу мөрәҗәгате таратылганчы, татарлар белән власть арасында шактый ыгы-зыгылар булып үткән.

Вятка губернасының Алабуга өязе татарларының* дини кысынкылыкларга каршы хәрәкәте 1897 ел исәп алуына кадәр күп еллар, бертуктаусыз диярлек, дәвам итеп килгән. Татар мәктәп-мәдрәсәләрендә рус класслары ачу, рус-татар мәктәпләре оештыру һәм шуңа охшаш башка чараларны тормышка ашыруны 1870 елның 26 март указы нигезендә күздә тотылган үзгәрешләр Вятка губернасы татарларын да хафага салган. Бу төбәктәге Кырынды, Төрдәле, Бетсемәс, Ямурза, Мукшур һәм Тойма авылларының «яңа керәшен» дип исәпләнгән татарлары 1871 елда үзләрен мөселман дип белдергәннәр һәм көчләп тагылган православиедән катгый баш тартканнар. Бу вакыйгалар, әлбәттә, җиңел бармаган. Хөкүмәт яңадан христиан диненә кайтару өчен төрле гамәлләр кылып караган, бәрелешләр булган, татарлар сөрген-төрмәләргә озатылган. Ләкин патша хөкүмәте теләгән нәтиҗәсенә генә ирешә алмаган. Шушы мәхшәрләр тынып та җитми, 1891 елдан башлап мөселман руханиларына рус телен белү мәҗбүри булачагы турында фәрман булып, ул да зур борчулар тудырган. «Татарларны чукындырачаклар, чукынмаганнарын Төркиягә куачаклар, шул турыда патшаның фәрманы чыккан» дигән хәбәр Алабуга, Малмыж һәм Сарапул өязләрендә дә тарала. 1894 елның язында бу төбәктән Төркиягә күчәргә әзерләнеп, бөтен малмөлкәтләрен сатып күченеп китүчеләр була**. 1897 елгы халык исәбен алуга бәйле, алдан таралган имеш-мимешләр, вазгыятьне тагын да куерткан. Казан, Уфа, Самара һәм башка губерналарда яшәгән мөселманнар шикелле үк, Вятка губернасының көньягындагы Алабуга, Сарапул һәм Малмыж өязләрендә

* Бу мәкаләдә телгә алына торган, элек Алабуга өязенә кергән татар авыллары хәзерге вакытта Татарстан Республикасының Алабуга, Менделеев һәм Әгерҗе районнарына карыйлар. Аларның кайберләре (мәсәлән, Чокырча (Средний Лог), Бетсемәс, Баржы-Омга пүчинкәсе һ. б.) хәзерге вакытта юк инде. Ә Бакыр Заводы (Варзино-Алексеевский) авылы хәзерге Удмуртия Республикасының Алнаш районында. Бу авылларның хәзер кайсы административ берәмлеккә керүләре һәр очракта да аерым искәртелмәде.

** Россиядә яшәгән мөселман татарларның Төркияне дини яклаучы итеп караулары, аңа сыенырга омтылулары һәм рухи коллыктан азат итәчәгенә өметләнүләренең Казан ханлыгы җимерелгәннән башлап XX гасырга кадәр дәвам иткән озын тарихы бар. 1930 елларда совет хөкүмәтенең мәчетләрне ябу һәм руханиларны эзәрлекләве чорында да татарларның күңел түрендә һаман Төркия ярдәменә ышану хисе яшәгән. Моңа дәлил итеп өлкән буын вәкилләренең хатирәләрен мисалга китерергә мөмкин. Мәсәлән, Бөек Ватан сугышы алды елларында Әгерҗе төбәге авылларында «менә Төркия аякка гына бассын — дин кайтыр» дигән сүзләр йөргәнлеге турында ишеткәнебез бар.

яшәгән татарлар арасында 1897 елгы жан исәбе алу кискен ризасызлык һәм каршылык хәрәкәтен тудырган*. Сарапул һәм Малмыж өязләрендә каршылык әлләни киң җәелмәсә дә, Алабуга өязе авылларында шактый сизелерлек булган.

Киров өлкәсенең дәүләт архивында сакланган, шушы халык исәбен алуга бәйле вакыйгаларны чагылдыра торган махсус документларның берсе «Дело о волнении магометанского населения в Елабужском уезде, вследствие недоразумений и ложных слухов по поводу предстоящей всенародной переписи в Российской империи»[5], дип аталган.

Булачак халык исәбен алуга карата ризасызлык чаткылары, Алабуга өязендә 1896 елның, язында күренә башлаган. Шул вакытта авыллар исемлеген төзегәндә Атау (Сосновый Юраш) авылы татарлары мәгълүматларны теләмичә генә биргәннәр. Әзерлек эшләренең ул вакытта ук башлануы гажәп түгел. Чөнки перепись буенча баш комиссиянең 1896 елгы февраль күрсәтмәсендә торак пунктлар һәм алардагы халыкның гомуми исәбен алу буенча мәгълүматлар тупларга кушылган була.

Аннан соңгы тоташ каршылыклар шул елның 7 декабрендә әлеге Атау авылында кабынып киткән. Сәбәбе — мөселманнарны чукындыру турында йөргән имеш-мимешләр, мәхәллә муллысы да халыкны тыя алмаган. Земство башлыгы 9 декабрьдә Алабуга имамы Хуҗаханов белән бергә шунда барып, халык исәбен алу турында татарча махсус брошюралар таратып, җайлап аңлаткач, халык беразга тынычланган. Вакытына күрә эшне зурга җибәрмичә, хакимияткә ярдәм күрсәткән мулла Әхмәтзәки Хуҗахановка «Губернские ведомости» газетасы аша рәхмәт белдерелгән.

Патша Николай Икенченең махсус фәрманы буенча исәп алуны үткәрү бөтен ил күләмендә 1897 елның 28 гыйнвар көненә билгеләнгән. Шуңа әзерлек йөзеннән 1896 елның декабрь аенда Алабуга өязенең волость идарәләре хуҗалыкларның махсус исемлекләрен төзүгә керешмәкче була. Ләкин татарлар моңа каршы чыга. 12 декабрьдә татар авылларында халык исәбен алуга каршы фикерләр көчәйгәч, полиция күзәтүе арттырылган. Шуңа да карамастан, 16 декабрьдә земство башлыгы Анисимовка Турай авылында хуҗалыкларны теркәргә ирек бирмиләр. Ахун һәм өч мулла белән полиция исправнигы шунда килә. Халык шау-шу күтәрә, чукындырудан һәм мәктәп-мәдрәсәләр төзүне тыюдан куркуын белдерә. «Исәп алучыларны кертәбез, ләкин берни дә әйтмәячәкбез» диләр. Песәй һәм Бәзәкә авылларының бөтен кешеләре дә шундый ук кызган хәлдә була, янаулар яңгырый. Ыгы-зыгы күрше-тирә авылларга тарала. Песәй, Турай һәм Әтәс (Куразово) авылларындагы каршылык турында шул көндә үк Вятка губернаторына телеграмма җибәрелгән[6]. Анисимов халыкка аңлату өчен Диния нәзарәте әгъзаларыннан берәрсен чакыртырга кирәк дип, губернаторга тәкъдим итә.

Шуннан соң, 17 декабрьдә Вятка губернаторы өязләрдәге исправникларга махсус циркуляр җибәрә. Анда кайбер өязләрдәге мөселманнар арасында ялган хәбәрләр таратылуы, ләкин полициянең көч кулланмавы, фәкать муллалар аркылы аңлату эшләре генә алып бару тиешлеге әйтелә. Циркулярның эчтәлеге белән өязләрдәге бөтен муллаларны таныштырырга тәкъдим ителә[7].

Вятка губернаторы 19 декабрьдә Малмыж һәм, аеруча Алабуга өязләрендәге мөселманнарның халык исәбен алуга каршы булулары турында Уфага мөфти Солтановка хәбәр итеп, аңлату эшләре үткәрүне сорап мөрәҗәгать иткән[8].

Ул арада Алабуга өязе исправнигы Таширев хәлләрнең катлаулы булуын, халыкның муллаларны да тыңламавын, Нәзарәттән вәкил килүен дә теләмәүләрен, бөтенесе бер фикердә булганлыктан, кулга алулар үткәрүдән тыелуын, коткы сүзләрен (чукындыру һ. б.) читтән килгән татарлар таратуын хәбәр иткән[9].

Өч авылның: Бәзәкә, Песәй һәм Турай халкы 20 декабрьдә беркемгә дә буйсынмый, көндез дә, төнлә дә авылларыннан узган ят кешеләрне туктатып тикшерәләр. Хәтта Песәй авылы җыенында, исправникны үтерү турында карар чыгарыла. Халык арасында

* Вятка губернасының татарлар яшәгән бүтән (Глазов, Уржум һ. б.) өязләре буенча архив мәгълүматларыбыз юк. Һәрхәлдә, ул төбәкләрдә дә каршылык хәрәкәте булмый калмагандыр.

солдатлар киләчәк дигән хәбәр тарала. Полиция яшерен күзәтчелекне тагын да көчәйтә. Губернатор Клингенберг менә шуннан соң — хәлләр шактый катлауланган (И. Заһидуллин да искә алган) белдерүен бастырып таратырга мәҗбүр булган[10]. Бу белдерү Алабуга өязенә 25 декабрьдә килеп ирешкән. Тик аның әлләни тәэсире булмый, муллалар эчтәлеген авыллардагы халыкка җиткергәч тә болганышлар тынмаган.

Диния нәзарәте үз нәүбәтендә, Эчке эшләр министры күрсәтмәсе нигезендә, 1896 елның 24 июлендә барлык мөселманнарга, шул исәптән Вятка губернасында яшәүчеләргә, халык исәбен алу максатларын аңлату өчен бөтен ахуннарга һәм муллаларга хәбәр ителүен, шул ук хакта 9 декабрьдә яңадан циркуляр белән искәртелгәнлеген губернаторга белдерә. Вятка губернаторының соңгы (20 декабрь) мөрәҗәгатеннән соң Нәзарәт Алабуга өязе ахуннары: Морт авылында Хәбибрахман Мәсәгутовка, Бәзәкә авылында Габделхаликъ Габделгалләмевкә, Көчек авылында Гатаулла Габделкәримевкә, шулай ук Малмыж өязе ахуннары: Адай авылында Хөснетдин Хисаметдиневкә, Түнтәрдә Ишмөхәммәт Динмөхәммәтевкә һәм Мәчкәрәдә Мөхәммәтшәриф Габделбәшәревләргә мөселманнарны яхшылап нәсихәт кылырга, халык исәбен алудан читләшеп калу шәригать буенча гөнаһ дип саналуы һәм закон буенча да катгый җаваплылыкка тартылуга китерәчәген әйтергә кирәклеген белдерә. Дини идарә губернаторга исәп алучылар итеп грамоталы мөселман кешеләре, ә руслар булган очракта татарча белә торганнары куелсын иде дигән теләген дә җиткергән[11].

Салагыш волосте халкының башкалардан ныграк хафалануы һәм халык исәбен алу үткәрелгәч, мөселман дине зарар күрмәячәге турында аларның министрдан вәгъдә телеграммасы сораулары 24 декабрьдә губернаторга хәбәр ителгән[12]. Полициянең яшерен тикшеренүләренә караганда, Турай һәм Салагыш муллалары үзләре үк халыкны котырталар диелә. Халык исәбен алуга каршы җыеннарда, Салагыш авылының йорт хуҗалары гына түгел, барлык гаилә әгъзалары, бөтен халык бер булып катнашкан.

28 декабрьдә телеграмма аша, Алабуга өязенең иң зур татар авылы Салагыш халкының (ул вакытта анда 2 750 кеше яшәгән*) аңлатулар нәтиҗәсендә, исәп алуга ризалык биргәнлеге белдерелә. Ләкин Баржы, Турай, Песәй, Сарсаз, Әтәс һәм Бәзәкәдә яшәүчеләрнең күпчелеге каршы булуы, муллаларның, хакимият вәкилләренең аңлатуларына һәм мөфтидән килгән кәгазьләргә ышанмаулары әйтелә. Губерна идарәсе бу хакта тагын мөфтигә хәбәр итеп, үгетләү өчен Нәзарәт әгъзаларыннан берәрсен җибәрүне сорый.

Халык һаман да буйсынмагач, декабрьнең соңгы көннәрендә, кулга алулар башланган.

Исәп алу турында Эчке эшләр министрлыгы 1896 елның 31 августында раслаган махсус инструкция буенча, перепись көненә (ягъни 28 гыйнварга) бер ай кала, әмма 20 көннән дә кичекмичә, эш башланырга һәм билгеләнгән көнендә тикшерү үткәрелергә тиеш була. Алабуга өязенең җирле хакимияте катлаулы шартларга карамастан, халык исәбен алу эшен башлаган. Рус, удмурт һәм чирмешләр яшәгән авылларда эш тыныч барган. Әмма 1897 елның 1 гыйнварына исәп алуга катгый каршы торучы татар авылларының саны тагын да ишәйгән. Ул арада полиция башлыгы Алабуга өязе татарларының халык исәбен алуга каршы эчтәлектәге ниндидер китапларны, Минзәләдән яшерен рәвештә алып кайтып, таратуларын да ачыклый. Исправник, халык арасында аңлату эшләре алып баруга ярдәмләшүләрен сорап, Алабуга өязенең эре җирбиләүче татар алпавытлары Ибраһим Халитов белән Котлымөхәммәт морза Бикмаевка һәм рус идарәчеләренә мөрәҗәгать иткән. Бигрәк тә Халитов полициягә зур ярдәм күрсәткән.

Губерна идарәсенә Алабуга өязеннән, көн саен диярлек, телеграммалар явып кына тора. Үгетләүләргә карамастан, 1897 елның 3 гыйнварында Морт һәм Мордывый авыллары, 5 гыйнварда Абалач татарларының, ә 6 гыйнварда Тирсә авылында исәп алучыларны кертмәүләре, төрлечә янаулары һәм куркытулары турында хәбәр ителә.

Исправник кайбер авылларның гына ризалашуын, башкалары каршы торуны дәвам итүләрен белдерә һәм күршедәге

* Чагыштыру өчен мисалга өяз үзәге Алабуга шәһәрен алсак, 1897 елда анда барлыгы 4 240 кеше яшәгән.

Минзәлә өязенә гаскәриләр китертелүе, бәлки, шомландырыр дип фаразлый, берничә кешене кулга алуын җиткерә.

Вятка губернаторы Казан хәрби округ штабына 7 нче гыйнварда мөрәҗәгать итеп, ихтыяҗ булган очракта, Малмыж һәм Алабуга өязләренә гаскәр кайдан китертелергә мөмкинлеген белешә[13].

7 гыйнварда Татар Көеге авылына исәп алу өчен Чиркәс волосте старшинасы Заикин, счетчик һәм Чиркәс авылының рус пүнәтәйләре белән килгәч Шаһигалләм Шаһиәхмәтов (үзе Ядегәр авылыныкы) «берсен булса да үтерегез, кыйнагыз...» дип халыкны котырткан һәм тегеләрне куып җибәргәннәр. Шул ук көнне Яңа Аккужа авылында земство начальнигы белән полициягә каршылык күрсәтелгәнлеге, 5 кеше кулга алынганлыгы һәм тагын да кулга алулар булачагы белдерелә. Өяздәге татар авылларының күбесендә исәп алып баруы хәбәр ителә.

Котыртучыларны полиция кулга алырга бик тырышса да, моны башкара алмаган. Чөнки татарлар үз аралары-ннан беркемне бирмәгәннәр. 8 гыйнварда өязгә губернатор үзе киләчәге турында хәбәр ителеп, аны каршыларга дип әзерлек үткәрелгән. Бу архив эшеннән аңлашылуынча, чынлыкта да, Вятка губернаторы Клингенберг 1897 елның гыйнвар аенда, халык исәбен алу алдыннан Алабугага махсус килеп киткән.

Губернаторның килүенә әзерлек чаралары белән бәйле рәвештә генә гаеплеләр кулга алынган. Бер көн (!) эчендә — 11 нче гыйнварда өяздәге 70 кеше беръюлы кулга алынган. Шуның нәтиҗәсендә, каршылык күрсәткән кайбер авылларда (мәсәлән, Яңа Аккужада) 13 гыйнвар көнендә халык исәбен алу башланган. Кулга алынучылардан 19 кеше төрмәгә ябыла, 23 кеше полициядә тотыла һәм 28 кеше тикшереп, сорау алганнан соң азат ителгән. Кулга алынучылар: Абалачтан Гыйбадулла Ситдыйков, Җәлалетдин Әминев һ. б. (барлыгы 15 кеше), Морттан Мәгази Миңнебаев, Мөхәммәт Мөхәммәткәримев һ. б. (бөтенесе 13 кеше), Яңа Аккужадан 11 кеше, Әтәстән 7 кеше, Бәзәкәдән Миңнехужа Гыйззәтуллин һ. б., Песәйдән Хөснетдин Нуретдинов һ. б., Сарсаздан Сабит Габдуллин, Тирсәдән Зәйнетдин Нәҗметдинев белән Галләм Ханнанов, Татар Дөмдөменнән Мөхәммәтрәхим Рәхмәтуллин, Иске Юраштан Әхмәтша Хәмидуллин, Шакир Абдуллин һ. б., Барҗы-Омга пүчинкәсеннән Мортаза Хәмидуллин. Полиция тарафыннан шул хәтле кешенең кинәт кулга алынуы татар халкын куркуга салган. Әлеге вакыйгадан соң гына каршылык күрсәткән авыллар буйсынырга мәҗбүр булганнар.

Шулай ук коткы таратуда гаепләнеп, Казан губернасы Мулла Иле авылының Фәхретдин Әхсәнов, Минзәлә өязе Әлмәтмулла авылының Сөләйман-гәрәй Әхмәтгәрәев белән Гыймазетдин Идрисов, Мамадыш өязе Кәркәвеч авылының Мөхәммәтрәхим Габбасов, Мамадыш өязенең Бөкмеш волосте белән Минзәлә өязенең Күзкәй волостеннән тагын 13 кешегә, Алабуга өязендә хөкем эшләре ачылган[14].

«Переписьтән соң татарларны чукындырачаклар, бу хакта бездә кәгазь бар» дигән ялган сүзләрне Азево исемле рус авылы кешесе Григорий Никонов Моргасов та 22 декабрь көнне тараткан икән. Шулай ук Яңа Чекалды авылының Максим Лаврентьев Шергин Салагыш кешеләренә «бөтен татарларны да чукындырачаклар һәм Салагыш авылында чиркәү төзеләчәк» дигән сүзләр әйткән. Аларны волость суды унбишәр көнгә генә арестка алынуларына Салагыш татарлары ризалашмыйча, губернатор исеменә шикаять язганнар[15].

14 гыйнвар телеграммасы белән губерна идарәсенә Яңа Аккужа, Морт һәм Абалач авылларындагы каршылык сындырылуы, исәп алучылар кертелүе җиткерелгән.

Архив документларыннан күренүенчә, Алабуга өязендә барлыгы 64 татар авылының 34 ендә һәм татарлар яшәгән Бондюг заводында халык исәбен алуга каршы чуалышлар булган[16].

Халык исәбен алу буенча Алабуга өязе комиссиясе рәисе М. Грачевның 16 гыйнвар көненә булган мәгълүматлар нигезендә югарыга язып җибәргән документын күздән кичерик. Беренче участокта 15 гыйнварга барлык авылларда да исәп алу үткәрелгән. Бары тик Абалач авылында гына тоткарлык булуы, ләкин тиешле чаралардан соң каршылык бетүе әйтелгән. Икенче участокта, татарлар котыртуы буенча,

өч удмурт авылы каршылык күрсәткән була. (Бу уңайдан Грахово волостендәге Иж-Бубый исемле удмурт авылы крестьяннары Михаил Федоров белән Михаил Черновларның эшләре хөкем чыгару өчен волость судына тапшырылган). Хәзер аларның буйсындырылуы, исәп алу 20 гыйнварга бетәчәге, өченче участокта рус һәм удмурт авылларында исәп алу уңышлы баруы хәбәр ителгән. Татар авылларыннан Тирсә, Тоба, Сокман, Чишмә һәм Яңа Кызылъяр исәп алучыларны кертүгә һаман каршы булулары, Тирсәдә земство начальнигы белән бергәләп 25 хуҗалыкта перепись үткәрелгәнлеге, тик счетчик Федоровны үтерү белән янаулары белдерелгән.

Дүртенче участокта Салагыш өязендәге зур авыллар, бигрәк тә, Яңа Аккуҗа, Турай, Песәй, Бәзәкә, Сарсаз, Баржы, Әтәс авыллары каршылыкны дәвам иткәннәр. Ләкин 13-15 гыйнварларда исәп алуга керешкәннәр.

Бишенче, алтынчы һәм җиденче участокларда исәп алу уңышлы бара диелгән. Бары тик Күрәк волостендәге татар авылларында ул соңрак башланган. Ә Морт, Салавыч (Вотский Юраш), Татар Дөмдөме, Ядегәр һәм Көек авыллары каршылык күрсәткән. Ләкин хәзер барысында да эш тыныч баруы әйтелгән.

Сигезенче участоктагы татар авыллары: Бакыр Заводы, Баржы Омга, Яңа Бәзәкә, Чокырча буйсынмаган булсалар да, хәзер эш җайга салынган.

Тугызынчы участокка бары тик Алабуга шәһәре керүе, анда хәзергә исәп алуга керешелмәгәнлеге, 19 гыйнварда башланачагы белдерелгән[17].

18-22 гыйнвар көннәрендә Вятка, Пермь, Казан, Алабуга, Мамадыш арасында 70 кешелек гаскәри команда кирәклеге турында шифровкалы телеграммалар белән хәбәрләшү булып алган. Алабугадагы җирле командада 30 гына кеше булганга, читтән өстәмә көч китертү мәсьәләсе күтәрелгән. Хәрби округ башкомандующие исеменнән 28 гыйнварга Мамадышка бер рота киләчәге, һәм, ихтыяҗ булса, шуннан Алабуга өязенә юнәләчәге искәртелгән[18]. Хәрби телеграммаларның соңгысы 29 гыйнвар көненә карый, анда «Алабуга өязенә гаскәри рота җибәрү кирәкме?» дип сорала. Губернатор исеменнән 30 гыйнварда андый ихтыяҗ үтеп киткәнлеге хәбәр ителә.

Алабуга исправнигы 29 гыйнварда бөтен татар авылларында да җан исәбе алу кәгазьләре тикшерелеп бетүен, бүтән каршылыклар һәм кулга алулар булмавын губернаторга хәбәр иткән. Губернатор, үз нәүбәтендә, 31 гыйнварда Эчке эшләр министрына губернадагы мөселманнар арасында халык исәбен алу уңышлы үтүен җиткергән. 1897 елның 27 февралендә Вятка губернаторы Алабуга өязе исправнигы Таширевның перепись вакытында мөселманнар арасындагы тәртипсезлекләрне бетерүдәге тырышлыклары өчен министр исеменнән рәхмәт әйтүне үтенеп тагын бер мөрәҗәгать иткән.

Хәзерге вакытта Киров өлкә архивы фондларында Вятка губернасында 1897 елгы исәп алуның бары тик бер — Алабуга өязе авылларының гына һәр гаиләне теркәгән беренчел бланклары сакланган (574 фонд). Бу өязгә кергән кайбер авылларның документлары Татарстан Милли архивында (991 фонд) саклана. Әлеге документлардан күренүенчә, халык исәбен алуга каршылык күрсәткән авылларның кайберләрендә генә исәп алучылар татар булган. Ягъни, Диния нәзарәтенең бу хактагы (исәп алучылар татар булсыннар иде дигән) теләге үтәлеп җитмәгән. Мәсәлән, чуалышлар булган авыллардан Бәзәкәдә исәп алучы татар кешесе Арслангали Хәмитов булса, Яңа Аккуҗа һәм Яңа Бәзәкәдә руслар К. Зорин һәм К. Дьяконов булганнар. Гаилә әгъзаларының тоткан диннәре кайбер авылларда «дин ислам» рәвешендә яисә «мусульманский» дигәнгә өстәп, «ислам дин» дип язылган. «Туган теле» графасында гадәттә «татарский» һәм «мусульманский» диелсә, кайчакта «тур.» дип («турецкий», төрки мәгънәсендә) теркәлгәннәр. Грамоталылык «мөселманча» яки «татарча» дип күрсәтелгән[19].

Халык арасындагы төрле аңлашылмаучылыкларны киметү йөзеннән халык исәбен алу буенча теркәү бланклары рус теле белән параллель ике телдә (рус-татар, рус-удмурт һ. б.) басылганлыгы билгеле. Татарчалы бланклар җитмәгәнлектән Алабуга өязенең кайбер татар авылларында русча-удмуртча бланклар кулланылган[20].

Гомумән алганда, 1897 елгы исәп алу нәтиҗәләре буенча Алабуга өя-

зендәге бөтен халык 241 005 кешене тәшкил иткән, шулардан мөселман татарлар 41 669 булган. Өяз үзәге Алабуга шәһәрендәге татарларның саны 479 кеше[21].

Югарыда тасвирланганнардан күренүенчә, башка төбәкләр белән бәррәттән, Вятка губернасында яшәгән татарлар арасында да халык исәбен алуга кискен каршылыклар һәм чуалышлар булып үткән. Мәсьәлә тагын да төгәлрәк аңлашылсын өчен кайбер архив документлары да тәкъдим ителә.

**ИСКӘРМӘЛӘР:**

1. Татар халык ижаты: Бәетләр. – Казан, 1983. – Б. 119-122; Кәримев Х. Җан исәбе алганда. – Казан, 1927. – 31 б.; Галәү М. Чүлмәк тулгач: «Канлы тамгалар» атлы тарихи романнан өземтәләр. – М., 1929. – 79 б.; Шул ук. Мөһаҗирләр. Тарихи роман. – Казан, 2000. – 303 б.
2. Загидуллин И. Перепись 1897 года и татары Казанской губернии. – Казань, 2000. – 223 с.
3. Там же. – С. 118.
4. Там же. – С. 119-120.
5. Киров өлкәсенең дәүләт архивы (КӨДА), 582 ф., 42 тасв., 189 сакл. бер.
6. Шунда ук, 1 кгз.
7. Шунда ук, 8 кгз.
8. Шунда ук, 3 кгз.
9. Шунда ук, 17 кгз.
10. Шунда ук, 19 кгз.
11. Шунда ук, 28-29 кгз.
12. Шунда ук, 21 кгз.
13. Шунда ук, 56 кгз.
14. Шунда ук, 74-77 б кгз.
15. Шунда ук, 81-81 б, 113-113 б кгз. Казан губернасында боларга охшаш хәлләрнең, ягъни рус кешеләренең татарларны котыртуы турында кара: Загидуллин И. Указ. соч. – С. 129-130, 138-139.
16. КӨДА, 582 ф., 42 тасв., 189 сакл. бер., 68-72 кгз.
17. Шунда ук, 78-80 кгз.
18. Шунда ук, 94-97 кгз.
19. Шунда ук, 574 ф., 9 тасв., 34, 107, 108 сакл. бер.; Татарстан милли архивы, 991 ф., 1 тасв., 41, 153 сакл. бер.
20. КӨДА, 574 ф., 9 тасв., 34 сакл. бер.
21. Первая всеобщая перепись населения Российской империи, 1897 г. – СПб., 1904. – Т. X. Вятская губерния. – С. 1-2.

### № 1. Сообщение земского начальника 4 участка Елабужского уезда Анисимова вятскому губернатору о сопротивлении татар при составлении списков хозяйств

17 декабря 1896 г.
№ 1957

Его превосходительству господину вятскому губернатору по Переписной комиссии.

12 сего декабря явились ко мне салаушский волостной старшина и волостной писарь и заявили, что 11 декабря они, составив списки хозяйств для всеобщей переписи в деревнях Сарсазе и Куразово и других, прибыли для этой цели в деревню Псеево. Но им заявили, что они не позволят составить списки хозяйств, так как опасаются, что после переписи будут открывать в татарских деревнях русские училища, а затем крестить сначала учеников, а потом и взрослых. Несмотря на убеждения в течение 6 часов, в деревне Псеево не дозволили обойти дворы для составления списка хозяйств. То же повторилось и в деревне Тураево.

Вследствие этого заявления я отправился 14 декабря в деревни Псеево и Тураево для убеждений исполнить беспрекословно все, что требуется положением о переписи. На сходе в деревне Псеево я разъяснил цель всеобщей переписи и обязанность каждого беспрекословно и совершенно правдиво дать необходимые для переписи сведения. После этого заявили мне, что они желали бы жить по-старому, что они опасаются, что после переписи будут строить в татарских деревнях училища, где будут обучать и по-русски, а затем, как говорят русские, будут крестить сначала учеников, а потом и взрослых, что если бы начальство только желало получить сведения, указанные в переписных листах, а не имело в виду другой цели, то оно могло бы все сведения получить от мулл и от волостных правлений. Несмотря на все мои и местного муллы разъяснения и убеждения, остались при своем убеждении и после объяснения моего об ответственности, которой они могут

# Отъ Вятскаго Губернатора

# ОБЪЯВЛЕНІЕ.

До свѣдѣнія моего дошло, что среди исповѣдующаго магометанскую вѣру населенія ввѣренной мнѣ губерніи распространяются ложные слухи по поводу предстоящей всенародной переписи. Считаю нужнымъ разъяснить, что перепись имѣетъ исключительно одну цѣль—вѣрный подсчетъ населенія. Никакихъ перемѣнъ послѣ нея не будетъ: школы (медресе и мектэбе) останутся тѣ-же, которыя существовали до-нынѣ, дѣтей никто силою не будетъ заставлять учиться; мечетей и молельней мусульманскихъ никто и не думаетъ закрывать. Поэтому каждый хозяинъ долженъ безъ всякаго страха давать показанія счетчикамъ, помня, что всякое сопротивленіе и неисполненіе требованій начальства влечетъ за собою наказаніе. Настоящее объявленіе предписываю объявить на сходахъ, вывѣсить въ волостныхъ правленіяхъ, училищахъ, мѣстахъ скопленія народа и раздавать отдѣльнымъ лицамъ въ случаѣ выраженнаго ими о томъ желанія.

**Вятскій Губернаторъ КЛИНГЕНБЕРГЪ.**

Вятка. Губернская Типографія. 1896 года.

ГА КО, ф. 582, оп. 42, д. 189, л. 19.

подвергнуться за неисполнение высочайшего повеления о переписи, заявили, что они не будут препятствовать счетчикам приходить в свои дома, но только говорить им ничего не будут.

По окончании схода явились в Псеево человек до 30 из деревни Сарсаза и требовали от волостного старшины, чтобы он возвратил им список хозяйств их деревни, составленный 11 декабря. После того как старшина объяснил им, что список находится в волостном правлении при делах, они отправились в свою деревню.

На собранном мною того же 14 декабря сходе в деревне Тураево происходило то же, что и в Псееве, то есть жители той деревни высказали те же опасения относительно переписи, как и псеевцы, и, несмотря на все мои разъяснения и объяснения, также заявили, что они не будут давать сведений для переписи. Когда крестьяне деревни Тураево начали со схода расходиться по домам, пришла толпа крестьян деревни Куразово, человек около 80, явившаяся на сход самовольно, без всякого призыва, и начала кричать, требуя от волостного старшины, чтобы он немедленно выдал обратно составленный им 11 декабря для переписи черновой список хозяйств деревни Куразово. Несмотря на многократные разъяснения старшины и мои, что список этот сам по себе ровно никакого значения не имеет, что они не имеют права его требовать и что списки по сему предмету находятся в волостном правлении, куразовцы, не слушая никаких разъяснений, настоятельно требовали от волостного старшины выдачи им списка, угрожая в противном случае избить или даже убить волостного старшину. А когда последний ушел в свой дом, где находился и я, крестьяне деревни Куразово Хузя-Ахмет Мухамет-Ганеев и Камалетдин Шамсутдинов и другие в числе более 10, ворвавшись в комнату, кричали, приступая к старшине: «отдай список»; «не отдашь, живым не выпустим из дома»; остальная толпа, отворив двери избы, стоя в сенях, кричала: «их надо бить», «убить надо». Избегнуть насилие со стороны толпы куразовцев удалось старшине только благодаря тому, что он обязался возвратить упомянутый список в общество деревни Куразово. Не доверяя словам, толпа угрозами лишить жизни принудила старшину выдать ей письменную подписку, с приложением печати, с обязательством возвратить список. О преступлении куразовцев составлен протокол и передан 16 декабря судебному следователю 2 участка Елабужского уезда.

Сообщая о сем, имею честь покорнейше просить указаний Вашего превосходительства для руководства мне в дальнейшем. Не признает ли Губернская переписная комиссия необходимым обратиться в Уфимское магометанское собрание с просьбой о командировании члена для убеждения и вразумления татарского населения Салаушской волости или же об обязании местных мулл исполнить обязанности счетчиков каждому в своем приходе, причем из них малограмотные по-русски заполнить могли бы переписные листы по-татарски.

Для разъяснений и убеждений вновь отправляюсь в деревни Тураево, Куразово и Псеево вместе с уездным исправником и елабужским муллой 18 декабря.

И[справляющий] д[олжность] земского начальника 4 участка Елабужского уезда: Анисимов.

Государственный архив Кировской области (ГА КО), ф. 582, оп. 42, д. 189, л. 9-11.

### № 2. Телеграмма вятского губернатора муфтию Султанову о противодействии мусульман предстоящей переписи

19 декабря 1896 г.

Магометанскому муфтию Султанову.

[В] Малмыжском, особенно Елабужском уездах магометанское население упорно противодействует мероприятиям по предстоящей народной переписи под предлогом опасения за неприкосновенность религии. Никакие увещания, объявления не помогают. Благоволите принять меры к разъяснению неосновательности опасений и убеждению мусульманского населения подчиняться распоряжениям, касающимся переписи. Буду ожидать ответа для донесения министерству.

Подписал: губернатор Клингенберг.

Послана 19 декабря 1896 года.

ГА КО, ф. 582, оп. 42, д. 189, л. 3.

### № 3. Из представления председателя Елабужской переписной комиссии М. Грачева вятскому губернатору

29 декабря 1896 г.
№ 273

Согласно предложению Вашего превосходительства, выраженному в письме от 20 декабря за № 8853, я совместно с земским начальником 4 участка Анисимовым и уездным исправником Таширевым выезжал в те селения, где возникли волнения между магометанами, для разъяснения им предстоящей всеобщей переписи и вразумления их. Волнения охватывают только Салаушскую волость. […] Основанием к отказу подчиниться переписи они, главным образом, указывают на распространяемый слух о том, что перепись населения среди магометан имеет конечной целью обращение их в христианство. Чтобы убедить насколько ложны подобные слухи, я по получении от Вашего превосходительства объявлений к магометанскому населению немедленно распорядился предварительно разослать их по тем селениям, где наиболее проявляется неподчинение переписи, а вслед за сим отправился туда же вместе с земским начальником и уездным исправником. […]

На сходах участвовали почти все наличные домохозяева и даже семейства их. Жители селения Салаушского, с населением более 500 хозяйств, изъявили готовность подчиниться переписи, причем для полного успокоения в том, что их не будут крестить, просили дать им бумагу, вроде удостоверения. Просьба их была удовлетворена. Жители селения Варзинского, состоящего из 230 дворов, отказались подчиниться переписи, хотя некоторые из них, более здравомыслящие, открыто выражая готовность подчиниться переписи, в то же время сами убеждали своих односельчан к повиновению, но такие убеждения встречали в толпе одни угрозы. Другие селения, именно: Сарсазское, Тураевское, Куразовское, Псеевское и Бизяковское, с населением в общем до 1 000 дворов, — проявляют явное нежелание допустить в свои дома счетчиков и давать им показания и только твердят одно: «сомневаемся», «не верим», «не желаем», «не согласны». […] Заметно также, что в каждом селении есть по несколько лиц, руководящих толпой, которая, в свою очередь, безотчетно повинуется им. Временное, на производство переписи, удаление таких лиц из среды своих обществ казалось бы мерой наиболее полезной для успеха переписи. […]

Председатель: [М. Грачев] (подпись).

ГА КО, ф. 582, оп. 42, д. 189, л. 47-49 об.

### № 4. Ответная телеграмма из штаба Казанского военного округа на просьбу вятского губернатора о необходимости военной команды

22 января 1897 г.
Подана 22/I. 1 ч. 15 м.

Командующий войсками приказал одной роте прибыть к 28 января в Мамадыш, откуда по требованию Вашему, обращенному к уездному воинскому начальнику, рота может быть направлена в Елабужский уезд. О получении телеграммы ожидаю ответа.

Генерал-лейтенант Бармин.

ГА КО, ф. 582, оп. 42, д. 189, л. 97.

### № 5. Рапорт елабужского уездного исправника Таширева вятскому губернатору о происшествиях во время переписи

2 февраля 1897 г.
№ 562

Его превосходительству господину вятскому губернатору елабужского уездного исправника рапорт.

Согласно циркуляру Вашего превосходительства от 30 декабря 1896 года № 1157 о представлении сведений о происшествиях, недоразумениях и выдающихся случаях, имевших место во время переписи, имею честь донести Вашему превосходительству — в дополнение к моим телеграммам — следующее: до 7 декабря между татарским населением

волнений не было, а с сего числа оно появилось в Черкасовской волости [в] деревне Сосновые Юрашы, но с помощью городского муллы Хузяханова мною было тотчас же через разъяснения о цели переписи прекращено, и более в этой деревне волнений уже не появлялось. С 12 декабря стали доходить до меня слухи, что в некоторых татарских деревнях замечается какое-то беспокойство, вследствие чего был усилен надзор за населением, но 16 декабря в деревне Тураево было уже исполняющему должность земского начальника Анисимову при составлении подворной переписи оказано сопротивление, и по прибытии моем в эту деревню с ахуном и тремя муллами крестьян нашел в сильно возбужденном состоянии, и все поголовно кричали: «Переписывать не дадим и никому не хотим верить, нас хотят крестить и открыть училище, распоряжение о переписи не от государя»; толпа была настолько взволнован[н]а, что при малейшей бы моей невоздержанности в словах она готова была сделать нападение. В то же время объехал я более многолюдные деревни Псеево и Бизяки, где нашел весь народ в таком же состоянии, в Бизяках из толпы слышались угрозы.

К 20 декабря получены мною уже более печальные сведения, что все крестьяне сказанных деревень днем и ночью останавливают проезжающих, спрашивают, кто, куда и зачем едет, почему проезд через эти деревни считался небезопасным, а в деревне Псеево будто бы составлен приговор, чтобы убить исправника. Желая какими-либо мерами сдержать раздражение крестьян этих деревень, я дал приказ урядникам, чтобы вся проселочная дорога, пролегающая этими деревнями на протяжении 40 верст, каждодневно исправлялась, и, назначив в каждую деревню по одному уряднику, обязал их по возможности узнавать имена подстрекателей; это распоряжение несколько умалило ярость крестьян, и уже на сходках более спокойно говорили: «Кого-нибудь исправник ждет, уж не солдат ли» — и находившимся в деревнях урядникам никакого насилия или ослушания в исправлении дорог не делали; затем было сделано по уезду распоряжение, чтобы задерживать и представлять ко мне всех лиц, которые ходят по деревням под разными сомнительными предлогами; подобных личностей с разных концов уезда было представлено ко мне 19 человек.

К 25 декабря были получены и прочитаны муллами присланные от Вашего превосходительства объявления о школах, медресе и мектебе; к сказанному объявлению крестьяне многих деревень отнеслись доверчиво и приняли уже еще более спокойный вид.

28 декабря я обратился с просьбами к помещикам Бикмаеву, Халитову (из магометан) и управляющим Дьяконову, Брызгалову, Скворцову и Осинскому оказать их влияние на магометанское население, моя просьба ими была исполнена, и действительно они принимали до конца переписи самое живое участие, а в особенности господин Халитов, благодаря которому мне весьма многие лица уже были известны в подстрекательстве, но до более удобного времени я лишен был возможности сделать распоряжение об арестах, так как толпа никого не хотела выдавать, и весьма зорко днем и ночью оберегали друг друга от арестов. Это усматривается из следующего случая: урядники Моралев и Бабушкин были командированы в деревню Псеево для ареста подстрекателя Хусаинова, куда ночью подъехали к его дому, но в это время жена его выбила стекла у наружных рам и закричала о помощи народ[у], почему урядникам пришлось уехать обратно, не произведя ареста Хусаинова.

К 1 января получил сведения, что волнение между татарами появилось еще в нескольких деревнях, и что будто бы в Мензелинском уезде проживают какие-то темные личности, знающие несколько иностранных языков, которые стараются употреблять меры к подстрекательству татар к недопущению переписи, и что татары Елабужского уезда ездят в Мензелинск на свидания с этими личностями; вследствие чего 2 января в частном плане командировал урядника Бабушкина (знающего татарский язык) в город Мензелинск следить и наблюдать за действиями елабужских татар; пробыл урядник в Мензелинске 4 дня, дознал, что из Мензелинского уезда елабужские татары привозят какие-то брошюры, но от кого — не дознал (о сказанных личностях было телеграммой сообщено мензелинскому исправнику).

3 января по получении от Вашего превосходительства разрешения на перепечат[ыв]ание из «Правительствующего вестника» именного указа государя императора от 19 декабря 1896 года о цели переписи (один экземпляр представлен Вашему превосходительству в городе Елабуге) я того же числа перепечатал и с нарочными разослал по уезду для обнаро-

дования; в некоторых деревнях полученный указ имел желаемый успех. Того же 3 января получил сведения из деревни Мортов Черкасовской волости, что крестьяне не допустили счетчиков и даже угрожали нанести им побои; по прибытии в эту деревню, где действительно нашел крестьян возбужденными и дерзкими (слухи говорят, что были вооружены ножами), ими самовольно был устранен от должности сельский староста и избран[о] по своему желанию другое лицо, которое по приезде со мной земского начальника явилось со знаком старосты, но хотя земский начальник и приказал немедленно ему удалиться и передать знак прежнему старосте, но этого он не исполнил, и как он, так и крестьяне кричали, что они его выбрали, а прежнего старосту уволили; увещания на крестьян деревни Мортов не только не действовали, но было заметно, что толпа все более и более ожесточалась, и несколько дней было такого времени, что положительно считалось пребывание должностных лиц в этой деревне опасным, из деревни никому не позволяли уезжать без того, чтобы предварительно не обыскать, заподазривая, не везет ли исправнику бумаги с согласием кого-либо на перепись. Ахун этой деревни прислал мне письмо, в котором сообщает о подстрекателях и опасном своем положении, но письмо не было найдено крестьянами лишь потому, что оно было спрятано под кожу хомута.

5 января в деревне Абалачеве мне также не пришлось уговорить крестьян, которых нашел не менее возбужденными, как и в Мортах, когда я прочел указ государя и хотел передать его старосте, то толпа закричала: «Указ вези с собой, нам его не надо», — и указ мне пришлось взять обратно. С 6 января послал отпуска некоторым муллам — ехать к муфтию, хотя и не находил в этом пользы, так как крестьяне во многих деревнях заявляли мне, что они муфтия не слушают, упорствующих двух мулл деревень Тураево и Бизяки отправил мерами полиции, и того же 6 числа уже были в уезде слухи, что в Мензелинском уезде вызвана команда.

7 января в деревне [Новое] Аккузино было оказано сопротивление исполняющему должность земского начальника господину Анисимову, но за произведенными 13 числа арестами обвиняемых в сопротивлении переписи счетчики были допущены. Того же 7 января, благодаря полученной мною от Вашего превосходительства телеграмме об объявлении населению Вашего приезда в Елабужский уезд и о применении положения об охране, я 8 числа объявил об этом населению и обязал: отвести в каждой деревне, где происходят волнения, по несколько квартир, исправлять дороги и делать их, насколько возможно, шире; полученное населением, это сведение о приезде Вашего превосходительства так подействовало на упорствующих, что мне была уже возможность сделать распоряжение производить беспрепятственно аресты подозреваемых в подстрекательстве лиц.

8 января были мною получены сведения, что крестьяне деревень Бизяки, Мортов и Абалачева на сходах говорят так: «Если бы перепись была по приказу государя, то исправник бы не стал ездить по деревням и нас упрашивать, а сажал бы в тюрьму» — и составили приговоры не допускать до переписи никакого чиновника. Это обстоятельство навело меня на мысль произвести аресты крестьян этих деревень в такое время, чтобы слух об этом по возможности скорее разнесся по уезду; для чего избрал базарный день 11 января в городе Елабуге и арестовал из этих деревень 70 человек; весть об этом действительно уже 12 числа обошла весь уезд и произвела на население желаемые для дела результаты, счетчикам была возможность приступить в упорствующих деревнях к переписи, которая ими была окончена 17 января, а 28-го — проверка переписных листов.

О всем вышеизложенном имею честь донести Вашему превосходительству.

Елабужский уездный исправник: Таширев.

ГА КО, ф. 582, оп. 42, д. 189, л. 132-135.

***Раиф Мәрданов,***
филология фәннәре кандидаты

**РЕЗЮМЕ**
Публикация кандидата филологических наук Раифа Марданова посвящена противодействию татар-мусульман Елабужского уезда Вятской губернии переписи населения 1897 г. Публикация подготовлена по материалам Государственного архива Кировской области.